

# ХАРИС МИННИАХМЕТОВИЧ ЗАКИРОВ

(1942)

Член Союза журналистов РФ, заслуженный работник культуры РТ.

Харис Закиров родился 15 ноября 1942 года в деревне Старое Аккузино Агрызского района, там же учился, а также посещал школы в Кучукове и Иж–Бобья. Окончил Казанский сельхозтехникум (1964) и Казанский государственный университет (1973). Со СМИ РТ сотрудничает более сорока лет, пробует себя в литературном творчестве.

Татарстанның атказанган хезмәткәре, журналист, язучы

Харис Миннәхмэт улы Закиров 1942 елның 15 ноябрендә Әгерже районы Иске Аккуҗа авылында Шәмсебану һәм Миннәхмәт Закировлар гаиләсендә дөньяга килә. Өч авылдагы – Иске Аккуҗа, Көчек, Иж-Бубыйдагы мәктәпләрдә укып, урта белем ала. Казан авыл хуҗалыгы техникумын (1964), Казан дәүләт университетын (1973) тәмамлый.

Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге әгъзасы, 40 елга якын Татарстанда нәшер ителгән газеталарда журналист хезмәтен башкара. 2000 елда аның “ Керпе мыегы”, 2008 елда “Әрәмәдә карама”, “Чәч бөртеге” (2021) исемле повесть һәм хикәяләр җыентыклары басыла.

Бөек Ватан сугышы тәмамлануга 60 ел тулу уңаеннан аның “ Арчалылар – Бөек Ватан сугышында” исемендәге 2 томнан торган хезмәте нәшер ителә.

Матбугат өлкәсендәге казанышлары өчен 1998 елда “Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре исеменә, 2002 елда “Мәгарифтәге казанышлары өчен” күкрәк билгесенә лаек булган Харис Миннәхмәт улы бүгенге көндә дә иҗат белән актив шөгыльләнә.

Тарих һәм мәдәни-мирас елында Татарстанның атказанган хезмәткәре, ветеран журналист Харис Закиров “Иж буенда өч авыл” исемле тарихи китабы белән авылдашларына бүләк ясады.